ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В ТАТАРСТАНЕ
2021
ТАТАРСТАНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

# "ТАТАР МАЛАЕ - 2021"

**Шәһәркүләм "ТАТАР МАЛАЕ-2021" бәйгесендә 2нче сыйныф укучысы Вәлиуллин Кәрим һәм 5нче сыйныф укучысы Мифтахов Әмирхан 3 урынны яуладылар.**













Май • 2021 ел • № 5 (41)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы



Гимназия күрке

## Безнең Диана булдырды!

Татар теленнән VIII Халыкара олимпиада призеры исеменә лаек булган 9нчы сыйныф укучысы Демашина Диана шәһәребез, гимназиябез данын яклады. Бу уңышка ул әдәбият фәненнннән системалы рәвештә шәһәр олимпиадаларында катнашып килү нәтиҗәсендә ирешә. Ул үзенең укытучылары Валеева Суфия Василовнага һәм Нурисламова Энҗе Әзһәмовнага чиксез рәхмәт хисләрен белдерәде.

Предмет буенча белемнәрдән кала, Суфия Василовна белән берлектә эшләгән проект эше актуальлеге, гимназиянең тарихы белән бәйле булуы белән Дианага зур өстенлек биргән. Ә инде чыгышының ахырында «Икенче гимназиям» җырын акапеллага башкаруы Диананың көндәшләренә шанс калдырмаган.

Гимназия директоры Гарифуллин А.Х., Диананы котлап, истәлекле бүләкләр тапшырды .

Афәрин, Диана! Сиңа яңаданяңа үрләр яуларга уңышлар юлдаш булсын!

**Азалия ӘМИНОВА**



## Татар малае

Татар малае нинди булырга тиешлеге хакында сорасалар, һич иренмичә, гимназиянең 2 нче сыйныфына юл тотыгыз. А.Х.Кадирова сыйныфында укучы Вәлиуллин Кәрим «Татар малае – 2021» шәһәркүләм бәйгесендә өченче урын алган!

Кәрим тырышып укый, саф татарча сөйләшә, җырлый, спорт белән шөгыльләнә, зурларга карата ихтирамлы. Менә шундый ул безнең татар малае!

**Адилә ХАНОВА**